**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3754**
**13.06.2024**

Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3660 номерлы Карары белән расланган торак урынны торак булмаган урын һәм торак булмаган урынны торак урын итеп күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3660 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2024 елның 16 февралендәге 1003 номерлы Карары редакциясендә) расланган торак урынны торак булмаган урын һәм торак булмаган урынны торак урын итеп күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 8, 9 пунктчалар өстәргә:

«8) яңадан планлаштырылган бүлмәләрнең техник планы;

9) бүлмәләрне яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә яңа бүлмә барлыкка килгән очракта, күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашырган өчен дәүләт пошлинасы түләү турында мәгълүматлар.»;

2) 3.5.4, 3.5.5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4 Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына мәгълүматлар кертү өчен, документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен, бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган региональ ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларыннан файдаланып, электрон формада Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (Росреестр) җибәрә.

3.5.5. Торак урынны торак булмаган урын яки торак булмаган урынны торак урын итеп күчергәндә, аны яңадан планлаштыру гамәлгә ашырылган һәм аның нәтиҗәсендә яңа бүлмәләр барлыкка килгән очракта, документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат, кабул итү комиссиясенең күпфатирлы йорттагы бүлмәләрне яңадан планлаштыру тәмамлануны раслый торган акты расланган (имзаланган) датадан башлап биш эш көненнән артмаган срокта, Росреестрга дәүләт кадастр исәбен яки дәүләт кадастр исәбен һәм гариза бирүченең яңадан планлаштырылган бүлмәгә (яңадан планлаштырылган бүлмәләргә) хокукын дәүләт теркәвен гамәлгә ашыру турында гариза җибәрә.»;

3) түбәндәге эчтәлектәге 3.5.6, 3.5.7 пунктлар өстәргә:

«3.5.6. Регламентның 3.5.2-3.5.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны башкару, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

3.5.7. Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы дүрт эш көне, кергән документлар комплектын ведомствоара комиссия тарафыннан карап тикшерү кирәк булган очракта - 11 эш көне тәшкил итә, Росреестрда гариза бирүченең хокукларын теркәү срогы муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов